# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ
# (IV чакырылыш)

IV чакырылыш чираттан тыш
утырыш
**КАРАРЫ**

2023 елның 08 декабре № 59 Урыссу ш.т.п.

«Милеккә җир кишәрлекләрен түләүсез алуга дәгъва кылучы өч һәм аннан күбрәк баласы булган, гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2012 елның 28 мартындагы 9 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2021 елның 13 сентябрендәге 731 номерлы карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының «Милеккә җир кишәрлекләрен түләүсез алуга дәгъва кылучы өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар исемлекләрен әзерләү тәртибе турында» 2012 елның 28 мартындагы 9 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында “Рәсми Татарстан” дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин